ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2022 Олы Кайбыч ав. № 50

2022 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында муниципаль юл фонды исәбеннән юл эшләренең муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп җирелә торган 2022 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында муниципаль юл фонды исәбеннән юл эшләренең муниципаль программасын расларга.

2. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында муниципаль юл фонды исәбеннән юл эшләренең муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 08 февралендәге 47 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәгълүматый-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның “01” февралендәге
50 номерлы карарына кушымта

**2022 елга муниципаль юл фонды исәбеннән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

**2022 ел**

**2022 елга муниципаль юл фонды исәбеннән**
**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре муниципаль программасы**
**ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2022 елга муниципаль юл фонды исәбеннән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре муниципаль программасы |
| Программа эшләүгә нигез | «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257 номерлы Федераль закон |
| Программаның заказчы- координаторы | «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчеләре | «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максаты | Урам-юл челтәрен, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын камилләштерү, автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту эшләрен үз вакытында һәм сыйфатлы башкару нигезендә автомобиль юлларыннан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле дәрәҗәдә транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | - юл хуҗалыгын ремонтлау эшләре күләмнәрен арттыру исәбенә гамәлдәге урам-юл челтәренең һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник торышын яхшырту;<br>- Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең юл хуҗалыгы белән идарә итү системасын камилләштерү;<br>- «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең юл хуҗалыгы өлкәсенә өстәмә инвестицияләр җәлеп итү. |
| Программаны үтәүчеләр | «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2021 ел |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2022 елда Программаны финанслауның суммар күләме:<br>- 14 292мең сум.<br>Финанслау чыганаклары:<br>2022 елның Татарстан Республикасы муниципаль юл фонды акчалары - 13 800 мең сум, 2021 ел Татарстан Республикасы муниципаль юл фонды акчаларының калган өлешләре - 492 мең сум күләмендә |
| Программаның үтәлешен тикшереп торуны оештыру системасы | «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты Программа чараларын гамәлгә ашыру мониторингын гамәлгә ашыра, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2012 елның 15 июнендәге 346 номерлы боерыгы белән расланган «Федераль юл фонды, Россия Федерациясе субъектларының юл фондлары, муниципаль юл фондлары акчаларыннан файдалану турында белешмәләр» 1-ФД формасы буенча муниципаль юл фонды |

| | |
|---|---|
| | акчаларыннан файдалану турында әлеге формада билгеләнгән срокларда белешмәләр бирә |

## 1. Кереш

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре муниципаль программасы 2022 елга муниципаль юл фонды исәбеннән (алга таба - Программа) муниципаль берәмлек составына керүче җирлекләр белән берлектә Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан, аерым алганда, Олы Кайбыч, Олы Подберезье, Иске Тәрбит, Надеждино, Хуҗа Хәсән, Мәлки, Багай, Колаңгы авыл җирлекләре белән берлектә эшләнде.

Программада 2022 елга Кайбыч муниципаль районы торак пунктларында гамәлдәге автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын ремонтлау һәм транспорт-эксплуатацияләү торышын яхшырту нәтиҗәсендә урам-юл челтәрен камилләштерү һәм үстерү перспективалары нигезләнә.

Әлеге Программаны гамәлгә ашыру районның икътисады үсешенә, халыкның яшәү шартларын яхшыртуга һәм районның торак пунктлары арасында ышанычлы элемтәләрне тәэмин итүгә, шулай ук муниципаль районның һәм җирлекләрнең хезмәт, табигый, җитештерү һәм инвестиция ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итәчәк.

Программада 2022 елга ремонт һәм төзекләндерү өчен планлаштырыла торган урамнарның исемлеге билгеләнгән, Татарстан Республикасы Юл фондыннан капиталь ремонт, юллар һәм корылмаларны, юл эшләрен финанс белән тәэмин итүгә ихтыяҗ күләмнәре билгеләнгән.

## 2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының юл хуҗалыгы торышын һәм үсеш проблемаларын анализлау

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларга җирлекләрнең муниципаль милкендәге торак пунктлар чикләрендә урнашкан муниципаль юллар, урам-юл челтәре һәм юл инфраструктурасы объектлары керә.

Хәзерге вакытта җирле әһәмияттәге муниципаль автомобиль юллары челтәре районның һәм җирлекләрнең социаль-икътисадый ихтыяҗларына тулысынча туры килми, бу район торак пунктларының тормыш-көнкүрешендә пассажирлар ташу һәм югалтулар куркынычсызлыгына куркыныч тудыра, шулай ук районның һәм җирлекләрнең социаль-икътисадый үсешен тоткарлаучы фактор булып тора.

Транспорт чаралары паркы һәм җирлекләр бюджетларының финанс мөмкинлекләре чикләнгән килеш автотранспорт хәрәкәте интенсивлыгы арту автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту күләмнәренең туплануына китерде, бу исә хәрәкәт шартларының начараюында һәм юлларның кулланучылар үзлекләренең сизелерлек кимүендә чагыла. Шул ук вакытта йөк ташуга ихтыяҗ структурасы үзгәрү исәбенә автомобиль транспортында йөкләр ташу күләмнәре арту

тенденциясе бар,  монда кулланучылар товарларын, урман продукциясен, төзелеш материалларын (вак таш) күбрәк йөк ташу роле арта.

Җирле бюджетларның финанс мөмкинлекләре чикләнгәнгә, җирлекләрнең юл хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлеге башлыча юл хәрәкәте куркынычсызлыгының элементар шартларын һәм транспорт чараларының өзлексез йөрүен тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Әмма бу эшләр җирлекләрнең барлык урам-юл челтәрен норматив таләпләргә туры китерү өчен җитәрлек түгел.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының юл хуҗалыгы өлкәсендәге төп проблемалар түбәндәгеләр:

- юлларның шактый өлешендә каты өслек булмау, юл япмасының ныклыгы һәм өслек тигезлеге буенча заманча йөкләнешләренә туры килмәве;

-юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру вәкаләтләрен үтәүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларында финанс чаралары җитмәү.

## 3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

Программаның төп максаты - Кайбыч районы  һәм җирлекләренең социаль-икътисадый үстерү өстенлекләрен исәпкә алып, юл хуҗалыгын ремонтлау һәм карап тоту эшләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару нигезендә урам-юл челтәренең юл өлешен камилләштерү, автомобиль юлларыннан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле дәрәҗәдә аларның транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- юл хуҗалыгын ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр күләмнәрен арттыру исәбенә гамәлдәге урам-юл челтәрен һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник торышын яхшырту;

- «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең юл хуҗалыгы белән идарә итү системасын камилләштерү;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең авыл җирлекләре юл хуҗалыгы өлкәсенә өстәмә инвестицияләр җәлеп итү.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2022 ел.

## 4. Программа чаралары системасы

Куелган максатны гамәлгә ашыру һәм Программаның бурычларын хәл итү өчен сроклар, башкаручылар һәм ресурслар буенча килештерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру таләп ителә.

Урам-юл челтәрен һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерү объектлары исемлеге Программага кушымтада китерелгән.

Программаны  гамәлгә ашыру барышында  чараларның сроклары һәм үтәлү өзлеклелеге үзгәртелергә мөмкин.

Гамәлдәге урам-юл челтәренең техник торышын яхшырту бурычын хәл итү максатларында Программа җирлекләрнең урам-юл челтәрен төзекләндерү эшләрен

башкаруны күздә тота. Эшләрне башкарганда һәркем файдалана алырлык файдалы казылмаларның җирле ресурсларын актив файдалану планлаштырыла. Автомобиль юлларын ремонтлау өчен Татарстан Республикасы муниципаль юл фонды акчаларын җәлеп итү планлаштырыла.

## 5. Программа чараларының ресурс тәэмин ителеше

Программа чараларын финанслауның төп чыганаклары буларак Татарстан Республикасы муниципаль юл фонды акчалары карала.

Программаның чараларын гамәлгә ашыруга барлыгы 14292 мең сум күләмендә акча планлаштырыла.

Программа чараларын гамәлгә ашыруга барлыгы 2022 ел муниципаль юл фонды акчаларын 13800,00 мең сум күләмендә һәм 2021 ел муниципаль юл фондларының калган акчалары исәбенә 492172,38 мең сум күләмендә планлаштырыла.

## 6. Программаны гамәлгә ашыру, идарә итү һәм үтәү барышын күзәтү механизмнары

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль юл фонды акчаларыннан нәтиҗәле файдалану һәм контрольдә тоту максатларында, Кайбыч муниципаль районының гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән Җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге нигезендә, 1 нче кушымтада каралганча 2022 елда муниципаль юл фонды акчаларыннан файдаланганда үзара хезмәттәшлек турында дүртьяклы килешү төзелә. Килешүнең яклары - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, «Главтатдортранс» ДКУ һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (килешү буенча):

- муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштырганда һәм файдаланганда методик ярдәм күрсәтә;
- муниципаль юл фондын төзү чыганаклары булган керемнәрнең җирле бюджетка керүенә мониторинг ясый;
- кануннар нигезендә муниципаль юл фонды акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп тора;
- муниципаль юл фондын төзү чыганаклары булып торучы керемнәр күләмендә муниципаль заказчының шәхси счетына акчаларның билгеләнгән тәртиптә күчерелүен гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (килешү буенча):

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларда муниципаль юл эшләре программаларын гамәлгә ашыруга җибәрелә торган муниципаль юл фонды ассигнованиеләре күләме турында

Кайбыч муниципаль районы тәкъдимнәрен исәпкә алган Татарстан Республикасында юл эшләре программасы проектын әзерләүне һәм раслауга бирүне гамәлгә ашыра;

- муниципаль юл фонды акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча методик ярдәм күрсәтә.

«Главтатдортранс» ДКУ (килешү буенча):

- объектлар исемлеген формалаштыруда методик ярдәм күрсәтә;
- объектлар исемлеге нигезендә юл эшләрен башкаруга контрактлар төзү максатларында муниципаль заказчылар белән уртак сатулар уздыра;
- расланган проект документациясе нигезендә объектлар исемлеге буенча чараларны гамәлгә ашыруны техник күзәтүне гамәлгә ашыра;
- башкарыла торган эшләрнең проект документациясенең, техник регламентлар таләпләренә, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә туры контрольдә тота, тикшерә;
- законнарда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге:

- Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган, Кайбыч муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле автомобиль бензинына, туры куылган бензинга, дизель ягулыгына, карбюратор (инжектор) двигательләре өчен мотор майларына акцизлардан кимендә фаразлана торган керемнәр күләмен финанслау күләме белән Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасын раслауны тәэмин итә;
- объектлар исемлеге буенча эшләр формалаштыру һәм финанслауны гамәлгә ашыра;
- Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2012 елның 15 июнендәге 346 номерлы боерыгы белән расланган «Федераль юл фонды, Россия Федерациясе субъектларының юл фондлары, муниципаль юл фондлары акчаларыннан файдалану турында белешмәләр» 1-ФД формасы буенча муниципаль юл фонды акчаларыннан файдалану турында әлеге формада билгеләнгән срокларда белешмәләр бирә.

## 7. Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның нәтиҗәлелеген бәяләүдә өстенлек иҗтимагый (социаль-икътисадый) нәтиҗәлелек күрсәткечләренә бирелә, чөнки ул программа чараларын гамәлгә ашырудан килгән нәтиҗәләрне тулы бәяли ала.

2022 елга муниципаль юл фонды исәбеннән
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре муниципаль программасына кушымта

## 2022 елга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге юлларында юл эшләре программасына кертелгән җирле әһәмияттәге объектлар исемлеге

| № п/п | Объект исеме | мәйданы, м2 | Гамәлдәге бәяләрдә капитал акча кертүләр, мең сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Соравыл ав., Киров ур. | 2025 | 3 645000 |
| 2. | Соравыл ав., Күл ур. | 675 | 1 350000 |
| 3. | Иске Тәрбит ав, Үзәк урамнан Киров ур. кадәр тыкрык | 652,5 | 1 255000 |
| 4. | Кече Подберезье ав., Зур Кызыл ур. | 1125 | 2 150000 |
| 5. | Морат ав., Болын ур. | 2925 | 5 400000 |
| **2022 елга муниципаль юл фонды планы буенча барлыгы** | | 10102,5 | **13 800000** |
| **2021 ел муниципаль юл фондларының калган акчалары исәбенә чаралар** | | | |
| ЮХК буенча чаралар, шул исәптән: | | | |
| Олы Кайбыч, Багай, Олы Подберезье, Хуҗа Хәсән, Мәлки, Коланғы урамнарына юл билгеләре һәм ясалма тигезсезлекләр урнаштыру. | | Юл билгеләре - 35 данә, ясалма тигезсезлекләр -2 данә | 492172,38 |
| **Барысы** | | | **14 292172,38** |